# МАГЪЛУМАТ
# Вестник

16+

cdum.ru

Печатный орган Центрального духовного управления мусульман России

ربيع الاول - ربيع الاخر рабигуль авваль - рабигуль ахир 1443 г. хиджри №5 (213) 2021 г.


# ПРАЗДНИК МИРА И ДОБРА - МАУЛИД АН-НАБИ

*Воистину, Аллаh и Его ангелы благословляют Пророка. О те, которые уверовали! Благословляйте его и приветствуйте миром.* (сура аль-Ахзаб, аят 56)




18 октября в Уфе состоялся праздник «Маулид ан-Наби». Торжественное мероприятие, организованное ЦДУМ России, прошло на площадке Башкирского академического театра драмы имени М.Гафури.

В связи с санитарно-эпидемиологическими предписаниями из-за пандемии коронавируса количество гостей было ограничено, но каждый из них пришел с искренним намерением отметить в джамаате День рождения Пророка Мухаммада (с.г.в.). Те, кто не смог побывать на благословенном маулиде, смотрели прямую трансляцию на официальной странице в Instagram talgat_safa_tajuddin.

Праздничный вечер начался с чтения сур Священного Корана, затем Верховный муфтий Талгат Сафа Таджуддин вознес д’уа. Шейх-уль-Ислам Талгат-хазрат обратился к единоверцам с проповедью, в которой напомнил об истории Ислама, о важнейших событиях в жизни завершающего Посланника Аллаhа (сг.в.) и сакральном смысле праздника «Маулид ан-Наби».

*Проповедь Верховного муфтия читайте на с. 4-8*

# 4 НОЯБРЯ - ДЕНЬ НАРОДНОГО ЕДИНСТВА



***Уважаемый муфтий!***

*Поздравляю Вас с Днем народного единства.*

*В истории России немало ярких, героических страниц, примеров гражданской сплоченности, отваги и мужества, которые проявлял наш народ в годину суровых испытаний, во имя свободы и независимости Родины.*

*Приверженность этим высоким нравственным ориентирам и ценностям, многовековым традициям честного служения Отечеству - главное, великое достояние, завещанное нам предкам.*

*Желаю Вам здоровья, успехов и всего самого доброго.*

***В.Путин***

***Уважаемый Верховный муфтий!***

Поздравляю Вас с государственным праздником - Днем народного единства.

Более четырех веков назад наш многонациональный народ встал на защиту Отечества. Любовь к Родине, единство, согласие и сплоченность помогли одержать победу над врагом, положить конец Смутному времени.

Сколько бы лет ни прошло - ценности, объединяющие всех нас, остаются прежними, помогают отвечать на любые вызовы, работать во имя развития и процветания России, повышения благосостояния миллионов наших граждан.

Желаю новых успехов, здоровья, мира, благополучия Вам и Вашим близким.

***М.Мишустин***

# СОВЕЩАНИЕ ПО ВОПРОСАМ РЕАЛИЗАЦИИ СТРАТЕГИИ ГОСУДАРСТВЕННОЙ НАЦИОНАЛЬНОЙ ПОЛИТИКИ ДО 2025 ГОДА

**28 октября в режиме видеоконференции прошло заседание Межведомственной рабочей группы по вопросам межнациональных отношений и Экспертно-консультативного совета при Межведомственной рабочей группе по вопросам межнациональных отношений.**

В совещании приняли участие: заместитель Председателя Правительства РФ (председатель Межведомственной рабочей группы) Дмитрий Чернышенко; руководитель Федерального агентства по делам национальностей Игорь Баринов; ответственные работники Аппарата Правительства РФ, Администрации Президента России и федеральных органов государственной власти; члены религиозных объединений, научных учреждений, экспертных организаций. ЦДУМ России представлял руководитель Администрации управления, председатель РДУМ Республики Башкортостан, муфтий Мухаммад Таджуддинов.

Главным пунктом повестки дня стал анализ плана мероприятий по реализации Стратегии государственной национальной политики Российской Федерации на период до 2025 года; также на обсуждение были вынесены другие вопросы, связанные с деятельностью федеральных национально-культурных автономий и иных некоммерческих организаций.

# Заявление Межрелигиозного совета России

**о недопустимости государственной регистрации в качестве товарных знаков обозначений, воспроизводящих религиозные символы**

В последнее время имели место случаи использования в качестве товарных знаков обозначений, воспроизводящих имена святых, их образы, а также символы веры и иные почитаемые верующими понятия и символы, в том числе в целях размещения их на алкогольной продукции.

Товарные знаки, предназначенные в том числе для маркировки алкогольной продукции, рассчитаны на круг лиц, в том числе верующих, считающих себя приверженцами той или иной религиозной конфессии, а информация содержащаяся в них носит публичный характер.

Нанесение изображений или имен святых на алкогольную продукцию, использование их в качестве товарного знака можно расценивать как действие, совершаемое в целях оскорбления религиозных чувств верующих и осквернения предмета почитания, в том числе имени святого.

Использование имени святого признаваемого религиозной конфессией, зарегистрированной в установленном порядке, или его изображения не может быть исключительным правом того или иного физического или юридического лица, не являющегося религиозной организацией или не учрежденного ею.

В этой связи совершенно недопустима государственная регистрация в качестве товарных знаков обозначений, воспроизводящих имена святых, их образы, а также символы веры и иные почитаемые верующими понятия, символы и семантически связанные с ними категории (то есть коммерциализация таких святых образов, символов, понятий), тем более для маркировки алкогольной продукции.

НОВОСТИ
ОНЛАЙН ТРАНСЛЯЦИИ МЕРОПРИЯТИЙ
И ПЯТНИЧНЫХ ПРОПОВЕДЕЙ

talgat_safa_tajuddin

# ВЕБ-СЕМИНАР «ПРОФИЛАКТИКА ЭКСТРЕМИЗМА И ТЕРРОРИЗМА»

**9 ноября РДУМ Оренбургской области и Министерство региональной и информационной политики организовали веб-семинар «Профилактика экстремизма и терроризма» для руководителей местных мусульманских организаций. В мероприятии принял участие и Председатель ЦДУМ России, Верховный муфтий, шейх-уль-Ислам Талгат Сафа Таджуддин.**



Верховный муфтий приветствовал организаторов и участников совещания. В своем выступлении Верховный муфтий подчеркнул, что несмотря на большую работу по профилактике экстремизма и терроризма, до сих пор не прекратились их проявления в обществе: «***Это важнейшая задача – сохранение и укрепление мира и согласия, необходима консолидация всех сил, взаимопонимание и координация действий духовенства традиционных конфессий и органов власти.***

*Здесь написано «профилактика религиозного экстремизма». Но делить экстремизм на религиозный и не религиозный очень трудно, наверно, потому что важнейшая роль религии и духовенства, несомненно, самой веры - это и есть профилактика экстремизма и терроризма. Потому что вся деятельность религиозных организаций, к какой бы традиционной конфессии не относились, это не только согласие и мир, но и взаимопонимание и взаимоуважение. Все посланники божьи, все Священные Писания и Кур'ан-Карим - завершающее Откровение Всевышнего всему миру направлено на то, чтобы взаимопонимание и взаимоуважение, мир и согласие было главным принципом во взаимоотношений людей. Пророк Мухаммад (с.г.в) говорил: «Не один из вас не будет настоящим верующим, пока не будет любить другим то, что любит для себя». Мы, прежде всего говорим о мире, о согласии, о взаимопонимании и взаимоуважении в нашей стране...*



*...Мы прекрасно помним, что в нашей стране делали террористы под прикрытием религии в 1990-е годы и в начале этого века. Мы видим, что сейчас происходит на южных границах, в Афганистане, что пытались делать в Сирии и Ливии, наслышаны про «арабскую весну». Проблема большая, тема важная...*

*Пророк Мухаммад (с.г.в.) говорил: «Кто увидит порицаемое дело, пусть прекратит его собственноручно, своей рукой или словом». То есть, когда вы видите какое-то нарушение порядка, совершение греха, ваше отношение к этому должно выражаться, прежде всего, в действиях.* ***И мы обязаны заниматься профилактикой экстремизма не время от времени, от одного семинара к другому, а постоянно. Это основная работа духовенства, повседневная.*** *Но какая часть прихожан охвачена проповедями в мечетях? Скажем откровенно, это 3-5 процентов верующих, тем более, в условиях пандемии. Поэтому мы ищем новые технические возможности, например, публикуем записи проповедей на сайте ЦДУМ России. Я призываю всех председателей региональных духовных управлений использовать ресурсы интернета, сайты и инстаграм, чтобы там размещать материалы. Несомненно, часть этих проповедей необходимо посвятить профилактике экстремизма».*

Верховный муфтий предложил проводить в регионах круглые столы с участием представителей традиционных конфессий и местных властей, и транслировать эти заседания на телеканалах, передавать по радио. Талгат Сафа Таджуддин поблагодарил председателя РДУМ Оренбургской области, муфтия Альфита Шарипова за порядок в общинах региона, сплоченность единоверцев во всех мусульманских приходах и мечетях, и выразил надежду, что семинар будет полезным для его участников.

Еще одним важным моментом в работе семинара стали лекции для имамов. Сначала с лекцией выступил профессор Амманского международного университета исламских наук, прямой потомок Пророка Мухаммада (мир ему), шейх Абдурраззак Ас-С'аиди.

Со второй лекцией к имамам обратился профессор ханафитского фикха Булгарской исламской академии шейх Мухамед Айман Аз-Захрави.

# ПРАЗДНИК МИРА И ДОБРА - МАУЛИД АН-НАБИ

*Продолжение. начало на с.1.*




«Бисмилләһир рахманир рахийм! Әлхәмдү лилләһи раббилгаләмийн, үәссәләтү үә ссәләмү галә рәсүлиһи Мөхәммәдин вә галә әлиһи вә әсхәбиһи әҗмәгийн.

Дин-мөъминдә газиз кардәшләрем, абзыйлар, апалар, егетләр, кызлар, килә алмыйча да, ерактан карап торучыларны да, илебездәге һәм бөтен галәмдәге мөъминмөъминә, мөслим-мөслимә кардәшләребезне, Рәсүл Әкрам с.г.в.-нең өммәтеннән булырга өмтылган газиз кардәшләребезне, җөмләбезне бу олы бәйрәм – Мәүлид-шәриф белән җанкүңелдән тәбрик итәм: “Әс- сәламу гәләйкүм вә рәхмәтүл-Лаһи Тәгалә вә бәрәкәтүһ!”.

Мәүлид-шәриф дип туган вакытка әйтелә. Дөньяга килү. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең туган көне бүген. Мең дүрт йөз елдан артык Расүл Әкрам с.г.в.-нең туганын без, иманлы бәндәләр, бәйрәм итәбез. Үзебезнекендә туганнарыбыз, балаларыбыз, оныкларыбыз, дусларыбыз белән искә алабыз.

Берәүләр: “Мәүлид-шәрифне, гомумән, мөселман туган көнен бәйрәм итергә тиеш түгел, бидәгать, яңылык ул”, - диләр. Алай дип әйтер идең, Аллаh Сөбханаһу вә Тәгалә Көрьән-Кәримендә пәйгамбәрләр хакында алар телендә әйтә:

وَالسَّلَامُ عَلَيَّ يَوْمَ وُلِدتُّ وَيَوْمَ أَمُوتُ وَيَوْمَ أُبْعَثُ حَيًّا

**“Аллаһның рәхмәте, сәламнәре булса иде миңа туган көнемдә, үлгән көнемдә һәм яңадан кубарылган көнемдә”,** - ди.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ сөннәт иттереп калдырды акыйка корбанын! Бала дөнъяга килде икән, ничек куанмаска ди! Ир бала туды икән – ике, кыз булды икән – бер корбан чалып, шуны гаиләңә,туганнарыңа, күршеләреңә таратасың, синең туган балаңа алар да куансын дип! Чөнки туу дигән сүз – үсү, дәвам итү. Шул килеш кенә калмый. Аллаһы Тәгалә шушылай итеп яраткан.

Атабыз Әдам г.с.-не туфрактан яратты, шул ук туфрактан Аллаһы Сөбханаһу вә Тәгалә ризыгыбызны да кылды. Куанабыз һәм шуңа сөенәбез! Кем икәнлегебезне шуның белән таныйбыз.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышлап әле аяк үрә өч ихласны укыдык. Аллаһны танытты Пәйгамбәребез с.г.в.. Ничек?!

قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ *(Куль-һүәл-лаһу әхәде).*
**“Әйт, хабибем, Мөхәммәд ﷺ: “Аллаh – Бер! Ялгыз!”**

اللَّهُ الصَّمَدُ *(Аллаһүс-Самәде).*
**«Аллаһы Тәгалә мәңге бар, беркемгә дә, бернигә дә мохтаҗ түгел».** *“Самәд” – “Буш түгел”* - дигән сүз.

لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ *(Ләм йәлиде үә ләм йүләд).*
**“Беркемнән тумады да, беркемне тудырмады да”.**

وَلَمْ يَكُن لَّهُ كُفُوًا أَحَدٌ *(Үә ләм йәкүл-ләһү куфүән әхәд).*
**“Аллаһы Тәгаләгә беркем тиң дә булмады”,** - ди.

**Шушы сүрәне бер кабат укысаң, Көрьән-Кәримнең өчтән бер өлешен укыган, өч кат укысаң – бер Көрьән укыган шикелле була әҗер-савабы!**



*Дәвамы, башы 1, 4 нче биттә*

**“Кем бу сүрәне ятратса, һичшиксез Җәннәткә керәчәк”**, - ди Пәйгамбәребез с.г.с.

Нидән?

**Беркемнән тумаган да, тудырылмаган да. Беркем дә Аңарга тиң дә булмаган. Ялгыз! Бер – Раббыбыз Аллаһ. Без – аның яратканнары!**

Аллаһы Тәгалә туа торган иттереп, тугач та үлә торган иттереп ятратты, дигән сүз.

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ **“Һәрбер жан ияce үлемне татыячак”**, - дигән сүз. Кем икәнлегебезне – бәндә, мәхлүк, Аллаһның ятраканы икәнлегеңне таныдың икән, дөньяга килүең дә, китүең дә үзеңнең кулыңда түгел икәнлекне тану дигән сүз.

Кайберәүләр уйлый: китүе үзеннән инде дип, килүе үзеннән булмасада. Килү әти-әнидән булса да, ләкин әти-әни сәбәпче генә. Сәбәпче булган өчен генә дә Аллаһ Сөбханаһу вә Тәгалә:

وَقَضَى رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا

**Аллаһ Раббың хөкем итте: “Аннан башка беркемгәдә бәндәчелек күрсәтмәскә, коллык күрсәтмәскә, тик Үзенә генә, Аның кушканын үтәп, тыйганыннан – тыелып, кушканча яшәргә тырышуыгызны Аллаһы Тәгалә кушты. Аннан, һичшиксез, Аллаһдан соң – ата-анаңа изгелек кылырга!».**

Дөньяга килүеңә сәбәпчеләр дә, тәпи йөрегәнеңәчә кадәр сине житәкләүчеләр дә, өйләнерлек, я кияүгә чыгырлык дәрәҗәгә житкәнчегә кадәр сине тәрбияләүчеләр дә, өйрәтүчеләр дә алар! Гомереңнең өчтән бер өлеше ата-ананың куенында уза, шөкерана булырга тиешле.

**Бөтенләй юктан бар Итүче!** Лыч балчык идек. Балчык икәнлегебезне белми идек, атабыз Әдам г.с.-дә. Аллаһ Сөбханаһу ва Тәгалә шушы дөньяга Әдам баласы иттереп күндерде. Жир йөзендә хәлифәсе иттереп ятратты. **Шушы дөньясына, адашмас, саташмас өчен, ата-ана гына булдырып бетерә алмас, шөгельләре күп, дөнья мәшәкатьләре белән**




**йөрегәндә онытылмас өчен, Аллаһ Сөбханаһу ва Тәгалә – әүвәл атабыз Әдам г.с., аннан соң йөз егерме дүрт мең илчеләр һәм пәйгамбәрләрне жибәрде.**

Берәүләр әйтә: **“Бездә руханилар юк, имамнар кирәк түгел, безнең белән Аллаһ арабызда арадашчылар (посредник) кирәк түгел”**, - ди. Әлбәттә, юк та! Беркем Аллаһ белән синең араңда киртә булу мөмкин түгел. Ләкин 124 мең пәйгамбәрләр - илчеләрнең ярдәмчеләре, алар арасында китапларыннан аятләрен, дәресләрен халыкка житкереүчеләр кем соң? Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.с. кем икәнлеген Аллаһы Сөбханаһу вә Тәгалә Көрьән-Кәримдә үзе әйтә:

مَا كَانَ مُحَمَّدٌ أَبَا أَحَدٍ مِنْ
رِجَالِكُمْ وَلَكِنْ رَسُولَ اللَّهِ وَخَاتَمَ النَّبِيِّينَ

**«Мөхәммәд, Мөхәммәд, Мөхәммәд, салләллаһу гәләйһи вә сәлләм! Сезнең ирләрегездән берегезгә дә ата булмады».** Ә хатыннарыгыздан кемгәдер ата булдымы ни? Әйе! Ир балалары да бар иде. Пәйгамбәребез с.г.с. күниясе Абдуль-Касыйм исемле беренче улы бар иде. Ул да вафат булды. Башка ир балалары да вафат булды. Пәйгамбәребез с.г.с. дөньядан үткән вакытында кыз балаларыннан хәзрәте Фатима исән иде әле.

Пәйгамбәр с.г.с. аврып, үлем түшәгендә ята, хәзрәте Фатима хәлен белергә килә. Елый. Борчыла. Пәйгамбәребез с.г.с. колагына гына тагы бер сүз әйтә. Хәзрәте Фатима елмая башлый. Хәзрәте Гәйшә, Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең иң кече җәмәгате, килеп сорый: “Нәрсә әйтте?”. Дәшми. Соңыдан гына, күпмедер вакыт үткәч кенә әйтә: “Елаганым шул булды – әтием вафат булуын, әҗәле житкәнлеген әйтте, аннары: “Минем туганнарым, якыннарымнан иң беренче син кайтучы булачаксың”, - диде”. Алты айдан соң хәзрәте Фатима вафат булды.

**«Мәхәммәд с.г.с сезнең ирләрегездән берегезгә дә ата булмады»** - ир балалары калмады. «Аның урынына мин булдым», - дип, бәлки берәрләре дәгъваламас өчендер.

وَلَكِن رَّسُولَ اللَّهِ وَخَاتَمَ النَّبِيِّينَ

**Бәлки Мөхәммәд (с.г.в) – Аллаһның илчесе булды. Бөтен пәйгамбәрләрнең дә йомгаклаучысы булды».** Аннан соң пәйгамбәрләр булмаячак. Никадәр заманына туры китереп, тәртипне өйрәтәбез диючеләр гасырлар буена булган булса да, хур булдылар. Безгә дә дөньяда жәннәт, коммунизм төзибез дип сөйләүчеләр күп булды. Ләкин үз күзебез белән кая барып житкәнлекне күрдек. **Дөньяда жәннәт булуы мөмкин түгел! Ләкин дөнья һәм әхирәт сәгадәтенә омтылу тиеш!**

**Мөхәммәд с.г.с. Аллаһның Илчесе һәм Пәйгамбәрләрнең дә йомгаклаучысы ул! Ә эшләрен кем дәвам итә?**

علماء أمتي كأنبياء بني اسرائيل

**Расүл Әкрам с.г.в: “Минем өммәтемнең галимәнәре – бәни Исраилнең пәйгамбәрләре шикелле”, - диде.** Илчеләре түгел, пәйгамбәрләре шикелле, диде.

*Дәвамы 6-8 нче биттә*




*Дәвамы. Башы 4-5 нче биттә.*

Көрьән-Кәрим белән Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең сөннәте белән дус булган, аны аңлап, халыкка дөрес иттереп җиткергән кешеләр, Аллаһның Хак илчесе – Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнән соң пәйгамбәрләрнең вазыйфасын үтәүчеләр. Шуңа күрә дә Пәйгамбәребез с.г.в: **“Юлга чыксагыз, икәү генә булсагызда сәфәрдә, берегез – имам, икенчегез мәзин булсын”**, - диде.

Җитәкче булмый торган булса, – **“Ул вакыттан бәндәнең җитәкчесе шайтан булыр”**, - диде Пәйгмбәребез с.г.в.

كُلُّكُمْ رَاعٍ، وَكُلُّكُمْ مَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ

**“Һәркайсыгыз көтүче”**. Имам үзенең мәхәлләсендә, авылында, шәһәрендә халыкка Аллаһның сүзен җиткерүгә мәсъвүль, Аллаһ каршында көтүче шикелле итетереп җавап бирә. Ата-аналары – балалары, гаилә өчен, остазлар – шәкертләр өчен, һичшиксез, җавап бирәчәкләр.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اذْكُرُوا اللَّهَ ذِكْرًا كَثِيرًا وَسَبِّحُوهُ بُكْرَةً وَأَصِيلًا

**“Сез дә, и, иманлы бәндәләрем! Аллаһ Раббыбызны оныта күрмәгез, истә тотыгыз! Күп иттереп Аллаһны искә алыгыз! Иртә, кичләрен дә Аллаһка тәсбихләрегезне әйтегез”, - ди.**

*“Күп”* – дигәне биш вакыт намаз. Күпме ул?! Фарыз ителгән вакытында илле тапкыр иде. Кем киметергә сорады Пәйгамбәребез ﷺ? Муса г.с.! ***“Минең өммәтемдә булдыра алмадылар. Киметергә Аллаһтан сора”**, - диде. Пәйгамбәр с.г.в. сорый. Кырык бишкә кала. Тагын сорый, Муса г.с әйтүе белән. Кырыкка кала. Утыз бишкә, утызга, егерме бишкә, егермегә, ун бишкә, унга. Аннары бишкә калганнан соң да, Муса г.с: **“Үти алмаслар. Минем өммәтем үти алмады, сора киметергә”**, - дигән вакытында, **“Аллаһтан оялам инде!”** – ди Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.*

**«Бишне үтәде икән өммәтең, иллене үтәгән шикелле иттереп әҗер-савaплары булыр», - диде Аллаһ Раббүл-Гыйззә.**

هُوَ ٱلَّذِى يُصَلِّى عَلَيْكُمْ وَمَلَٰٓئِكَتُهُۥ لِيُخْرِجَكُم مِّنَ ٱلظُّلُمَٰتِ إِلَى ٱلنُّورِ ۚ وَكَانَ بِٱلْمُؤْمِنِينَ رَحِيمًا

**“Ул Аллаһ Раббыгыз сезгә рәхмәтләрен явдырып тора,** (“*явдырачак*” кына дигән сүз түгел. Бертуктаусыз Аллаһ Тәгалә сезгә рәхмәтләрен явдырып тора), **Аллаһның рәхмәт фәрештәләредә бу дөньяның бозыклыкларыннан, караңгылыкларыннан нурга, Аллаһның рәхмәтенә чыгарыр өчен. Аллаһ Раббыбыз шулай иттереп, иманлы бәндәләренә, берлегеен таныганнарга, мәрхәмәт-шәфкать Иясе булды һәрвакытта».**

تَحِيَّتُهُمْ يَوْمَ يَلْقَوْنَهُ سَلَامٌ وَأَعَدَّ لَهُمْ أَجْرًا كَرِيمًا

**«Иманлы кешеләр Раббыларына юлыккан көндә дә, Аллаһтан аларга сәлам: “Хуш килдегез!”, - дип генә булачак». Һәм “Аллаһ Раббүл-Гыйззә аларга олы әҗерләрендә әзерләдe”, -** дип Көрьән-Кәримендә әйтә.

**Пәйгәмбәребез с.г.в безгә әүвәл – Аллаһны һәм Аллаһка чын иманның ни икәнлеген аңлатучы булды.** Бүгенге көнебездә без ике миллиардка якын мөселманнар, Әль-хәмдуллилаһ. Ләкин җир йөзендәге бөтен инсаният соң Илче, Пәйгамбәр с.г.с. өммәте. Берүләр әйтүе мөмкин: “Кая ул, ничек?”, - дип. **Аллаһның каршысында без бөтенебездә Пәйгамбәребез с.г.в. өммәте.** Җир йөзендә җиде миллиардтан артык халык була торган булса, Көрьән-Кәримдә Аллаһ Сөбханаһу вә Тәгалә:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ

**“Сине яраткан, бар иткән Аллаһ исеме белән укы”**, - дигән аят, Пәйгамбәр с.г.в. кырык яшендә ингән чагыннан алып, дөнья беткәнчегә кадәр, җир йөзендә белсә-белмәсә дә, теләсә-теләмәсә дә, бөтенебез Пәйгамбәребез с.г.в. өммәте.

Һичшиксез, без, моннан мең дүрт йөздә утыз өч ел элек Болгар бабаларыбызның Ислам динен үз теләк-ихтыярыбыз, Аллаһ насыйп итүе белән кабул иткәнгә күрә, гасырлар буена бераз шау-гөрләр булган булсада, җитмеш ел буена динсезлекне тагырга маташкан булсалар да, ул вакытта да көлдек тә, елмайдык та, хәлебездән җиткәнчә Аллаһка гына кол булырга тырыштык. Бигрәк тә эти-әниләребез, әби-бабаларыбыз: **«Безнең дәүләт диуана түгел ул, җитер бер көн, манаралар да күтәрелер, азаннар да әйтелер. Динсез яшәү мөмкин түгел икәнлеген аңларлар»**, - дип, үткән ел референдумда, Аллаһга шөкер, **“Аллаһка ышану һәм традицион рухиәхлакый кыйммәтләр безнең ата-бабаларыбызның мирасы”** - дигән сүзләр Конституциягә керде!

**Иман – әүвәл күңелдә! Кайнап чыгырга тиешле! Күңелебез белән шуңа беркетелергә тиешле.**

Пәйгамбәребез с.г.в. өммәте дигәндә, безнең бүгенге көнебездә өстебезгә искиткеч зур мәсүлият – җаваплылык төшә. Берәү сорар: “Ярый, без, Әль-хәмдуллилаһ өммәтел-иҗәбә (*Аллаһның Хак Илчесе Мөхәммәд с.г.в-нең өндәвен ишетеп, кабул иткән өммәте!*), ә калганы нинди өммәт булсын соң ул?”. Юк дип йөргәне дә, азып-тузып йөргәне дә, алар да – өммәт.

*Дәвамы. Башы 4-5 нчы биттә.*

Борынгыларның салаватларына карагыз:

اللّهم صلِ على سيدنا محمد بعَدَدِ مَنْ صَلىَّ عَلَيْه

**“Я, Раббым Аллаһ, хабибең Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә, аңарга салават әйткәннәрең санынча салаватны җиткерсәң иде”.**

اللّهم صلِ على سيدنا محمد بعَدَدِ مَنْ لم يصل عَلَيْه

**“Я, Раббым Аллаһ, хабибең Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә салават әйтмәгәннәрнең санынча да салаватлар җиткерсәң иде! Җир йөзендә күпме кеше бар, шуның кадәр салаватларыбызны җиткерсәң иде, рәхмәтләрне явдырсаң иде!”,** - дип догалар әйтелгән...

Пәйгамбәребез с.г.с азган-тузганнар арасына да, кире каккан-нар арасына да Аллаһның сүзен җиткерергә тырышты.

Күбесе монда - мәчетләребездә, мәхәлләләребездә хезмәт иткән хәзрәтләр, гилем һәм дәүләт ияләре, мәчетлребезгә йөри торганнарыбыз – беркемгә дә каты бәрелмәскә, йомшак мөгъәмәләдә булырга, үрнәк булырга тырышырга, балаларыбыз, оныкларыбызга ничек иттереп сөйли торган булсак, бөтен бәгъеребез, мәхәббәтебез, йөрәгебез белән, шушылай иттереп башкаларга да җиткерергә тырышырга тиешле. Кимчелек, хаталарын гына күреп, аның өчен тәнкыйть итергә, сүгергә түгел, ә ачык чырай һәм тәмле сүз белән өндәү кирәк.

Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә карыйк! Аллаһ Раббул-Гыйззә Көрьән-Кәримендә безне сөендерә:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ قُلْ إِنَّمَا يُوحَىٰ إِلَيَّ أَنَّمَا إِلَٰهُكُمْ إِلَٰهٌ وَاحِدٌ ۖ فَهَلْ أَنتُم مُّسْلِمُونَ

**“Хабибем, Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләмне сезгә җибәрмәдем, - мәгәр җибәрдем исә, бөтен галәмгә рәхмәтем иттереп җибәрдем”, - ди Аллаһы Тәгалә.** Бөтенесе Аллаһның яраткан бәндәсе, бу дөньяга килергә лаек тоткан аны! **“Шуның өчен дә хабибем, Мөхәммәд, әйт бәндәләремә: “Миңа вахи килә, Аллаһ шулай дип әйтте, җиткерергә кушты: “Тәңрегез, Раббыгыз – Бер”** - дип.

فَهَلْ أَنتُم مُّسْلِمُونَ

**“Сез – җир-күкләрне, бөтен галәмләрне Яратучы Раббысы Аллаһка иманып тапшырылучылар - мөселман буласызмы инде?”,** - ди. *“Мөселман булу”* дигән сүз, башыңа күләпүч кию генә, я муеныңа ай тагу гынамы? Аның белән генә түгел! **Аллаһка коллык күрсәтү дигән сүз. Үзеңне Аңа - мәрхәмәт-шәфкать Иясенә тапшыру дигән сүз һәм гамәл!**

إِنَّ اللَّهَ اشْتَرَىٰ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ أَنفُسَهُمْ وَأَمْوَالَهُم بِأَنَّ لَهُمُ الْجَنَّةَ

**“Аллаһы Тәгалә иманлы кешеләрнең җаннарын да, үзләрен дә Җәннәт бәрабәренә сатып алды”, - ди Көрьән-Кәримдә.**

Берәү әйтер: “Үзенекен кем сатып ала инде?”. **“Аллаһ Тәгалә буш булмас, сезнең гомерегез, бер минутыгыз, бер секундыгыз әрәмгә үтмәс”, - дигән сүз.**

Шуңа күрә дә Аллаһның диненнен Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә, ничек иттереп җиткергәненә карыйк. Нәрсә ул туган көнен бәйрәм итүебез? Аллаһ насыйп итсә, хәзер мөнәҗәтләрне ишетәбез, бөтен дөнья бүген сайрый, ләкин без Пәйгамбәребез с.г.в лаек өммәтме?

**Пәйгамбәребез с.г.в.: «Ислам дине бишкә нигезләнде, - ди. - Аллаһны тану, анан соң намаз, ураза, зәкәт, хаҗ».** Кем инкарь итә ала Аллаһны? Дөнья фән-галимләре дә таный! Бөтен дөньяга танылган галимләрнең дә бөтен барлыкны бар Итеүченең тәртибенең ни икәнлеген танымыйча хәле юк. Аллаһы Тәгалә: **“Үзегезгә генә карагыз. Кем соң сез?”,** - ди. Үзебезгә караганда да исебез китә...

Бергәләшеп, ата-ана моңа өйрәтергә, аңлатырга тиешле. Сабыйларыбызга рәсем төшерергә, чит телләрне, музыка өйрәтергә генә түгел (анысы да, һичшиксез, кирәк, сеңгән чагында), Аллаһны Раббыбызны, бу дөньяда без кем икәнлегебезне дә танытырга кирәк.

Ялгыз укыган намазың да – намаз, ләкин бергәләшеп укыйбыз икән, мәчеттәме, өйдәме балаларыбыз белән, егерме җиде өлеш артык, биш көн намазның әҗер-савабы! Ни өчен бергә? Менә хәзер авызларыбыз да капланган, кергәндә дә тикшерәләр, нәүмиз булдык. Ялгызлыкка бер дә Әдәм баласы чыдый алмый. Ялгызлык Аллаһка гына килешә! Әдәм баласын, Аллаһы Тәгалә пар итеп яраткан, хәтта башка җан ияләрен дә. Бердәм булып, бер-беребезгә терәк, кардәш булырга!..

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ إِخْوَةٌ

**“Дөреслектә иманлылар җан-кардәшләр”, - ди Аллаһ Сөбханаһу вә Тәгалә.**

Уразабызда көне буена ач йөрибез. Ни өчен?

لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

**“Шәйәтки тәкъвалардан булырсыз ураза тотып, фәкирьегез дә, байларыгыз да, башкаларның хәлен акыл, йөрәк белән генә түгел, карыныгыз белән дә сизерсез дә, йомшагырак, мәрхәмәтле, шәфкатьлерәк булырсыз”, - ди Раббыбыз Аллаһ.**

Зәкәт бирү - турыдан-туры, малыңнан ярдәм. Хаҗга бару исә, сәяхәт кылу гына түгел, ә Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең йөргән урыннарын, аны тәүлектә егерме дүрт сәгать буена искә төшереп, мәхәббәтеңне арттыру, шундый эсселәрдә иманыбыз куәтләнер өчен һәм бөтен җир йөзендәге бәндәләр, атабыз – Әдам г.с., анабыз – Хаввадан икәнлеген, бертуганнар икәнлеген хәтерләр өчен. Милләтенә, төс-кыяфәтенә, иленә карап, беркемнең дә артыклыгы да, кимлеге дә юк икәнлеген искә төшереп, гомер буена онытмас өчен бит хаҗ.

عن عبد الله بن عمرو بن العاص -رضي الله عنهما

*Габулла ибне Гәмр ибнель-ас радыяллаһу ан'һумәдән ривәять әйтелә* (Пәйгамбәр с.г.с-нең якын сәхәбәләреннән, атасы соңыннан Мысыр губернаторы да булган).

أن رجلاً سأل رسول الله صلى الله عليه وسلم

*“Бер кеше Пәйгамбәр с.г.с-нән сорый:* أي الإسلام خير؟ ***“Я, Расул Аллаһ, исламның кайсысы хәерлерәк?*** *(Аллаһның кушканнары күп).* ***Иң хәерлесе, җыңелерәге кайсы?***”, - дип.

قال: تُطعِم الطعامَ وتقرأ السلامَ على مَنْ عَرَفت وَمَنْ لم تَعْرِف

**“Үзең ашаган ризыгыңнан башкларыны да сыйларсың, белгәнеңә дә, белмәгәнеңә дә сәлам бирерсең!”, - дип җавап бирә Рәсүле Әкрам с.г.в.**





*Азагы. Башы 1, 4-7 нче битләрдә*

Ни дигән сүз? **“Бер-берегездән бизмәгез, сәлам дә бирегез, ризыкларагыз белән дә уртаклашыгыз, дус-кардәш булып яшәргә тырышыгыз”**, - дип Пәйгамбәребез с.г.в. өйрәтеп калдырды һәм бәндә булуның беренче кыяфәте, беренче мизаны - үлчәүе итеп, Аллаһ Раббул-Гыйззә Пәйгамбәребез с.г.в-гә җиткерергә кушты. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә хабибе Мөхәммәд с.г.в.не мактап та әйтә:

فَبِمَا رَحْمَةٍ مِّنَ اللَّهِ لِنتَ لَهُمْ ۖ وَلَوْ كُنتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لَانفَضُّوا مِنْ حَوْلِكَ ۖ فَاعْفُ عَنْهُمْ وَاسْتَغْفِرْ لَهُمْ وَشَاوِرْهُمْ فِي الْأَمْرِ

**“Аллаһның нинди генә рәхмәтләре белән син йомшак күңелле булдың, әгәр дә әче телле, каты бәгьерле булсаң, синең тирәләреңнән алар качып киткән булырлар иде. Син, хабибем, Мөхәммәд с.г.в, гафу ит, кичер кешеләрне, Аллаһтан да ярлыкауны сора (алар өчен генә түгел), Аллаһның динен алып баруда алар белән киңәшләшә күр”**, - ди. Пәйгамбәребез с.г.в. киңәшер булды.

فَإِذَا عَزَمْتَ فَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُتَوَكِّلِينَ

**“Инде ныклап ниятләдең икән, Аллаһга тапшыр. Дөреслектә Аллаһы Тәгалә Үзенә тапшырганнарны сөя Ул”**, - ди.

Пәйгамбәребез с.г.в бер сүзендә әйтә: “Җабраил г.с. миңа килеп шулай диде: “И, Аллаһның хабибе! Әйт шушы сүзләрне:

اللَّهمَّ ربي استُرني بالعافيةِ في الدنيا والآخرة

**“Я, Раббым Аллаһ! Бу дөньяда һәм әхирәттә өртсәң-капласаң иде Син мине саулык-сәламәтлек, эшләрдә – уңлык, бәрәкәт белән”.**

Бүген ничек прививкаларны ясыйбыз, шуның шикелле бу доганы да укырга, һичшиксез, кирәк. Ләкин аңа кушырга:

اللَّهمَّ ربي استُرني وَأهلي وذُرّيتي وَجميع أمّةِ حَبيبك محمد صلى الله عليه وسلم بالعافية في الدنيا والآخرة

**“Я, Раббым Аллаһ, пәрдәләсәң, капласаң иде мине дә, туганнарымны да, нәселемне дә, Пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең бөтен өммәтен дә саулык-сәламәтлек, иминлек белән дөнья-әхирәттә”**, - дип дога кылдың исә, **“Бу дога һичвакытта кире кагылмас”, - ди.**

Рәсүл Әкрам с.г.в. бер сүзендә: **“Кем көненә йөз тапкыр:**

لا إله إلا الله الملك الحق المبين

**“Аллаһтан башка Тәнре юк, Чын, Хак, ачыктан-ачык Падишаһыбыз Ул, Хуҗабыз”**, - дип әйтте исә,

إسْتَفْتَحَ أبْوابَ الرِّزْقِ

**«ул бәндә, Аллаһтан ризык ишекләрен ачкан булыр,**

ونفت عنه الفقر

**фәкирьлектән котылыр,**

وَاسْتَقْرَعَ أبْوابَ الجنة **Җәннәт ишекләренә каккан булыр”, - ди.**

و وقي بها فتنة القبر **“Кабер газабыннан да ул сакланган булыр”,**

اتَتْهُ الدنيا وَهِيَ راغِمَة **“Дөнья аңа агып килер, дөнья теләмәсәдә”.**

وَيَخْلُقُ الله تعالى مِن كلِ كلمة مَلَكا يُسَبِّحُ الله تعالى وتَغْفِرُ لَهُ

**“Ул сүзләрнең һәрбер хәрефе саен Аллаһы Сөбханаһу вә Тәгалә фәрештә яратыр һәм Кыямәт көненә кадәр бу бәндә Җәннәткә кереп, гонаһлары гафу ителгәнчегә кадәр, Аллаһны олыларлар, бу бәндәгә ярдәм итерләр»**, - ди Пәйгамбәребез с.г.в.

Менә шундый мөбәрәк затның өммәтебез, бүген мәүлид көне тәмамланып килә, ләкин ае дәвам итә, гомерләребез дә булса иде. Бездән соң балаларыбыз, оныкларыбыз да Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмнең чын өммәте, Хак Тәгаләнең чын бәндәсе, колы булып яшәүләребезне Үзе насыйп кылсын! Мәүлид-шәрифләребез мөбәрәк булсын! Әс-сәламу гәләйкүм вә рәхмәтул-Лаһи Тәгалә вә бәрәкәтуһ!



Завершив выступление, Талгат Сафа Таджуддин вручил награду ЦДУМ России – медаль «Аль-Игътисам» («Сплоченность») Марсу Шагиеву, внесшему весомый личный вклад в укрепление традиционного Ислама в Башкортостане.

Далее с приветственной речью выступил советник по вопросам религиозного образования Совета по государственно-конфессиональным отношениям при Главе РБ Руслан Карамышев. Он передал поздравление от председателя Совета Азата Фаттахова и отметил, что, несмотря на непростые времена, в республике не прекращается процесс духовного возрождения.

Ведущие мероприятия – имам-хатыб мечети «Ихлас» Мухамет Галлямов и заслуженный артист Республики Башкортостан, студент РИУ ЦДУМ России Махмуд Фатыхов с особым эмоциональным настроем приглашали на сцену участников литературно-музыкальной программы. Мунаджаты, песни и стихи, посвященные любимому Пророку (с.г.с.), исполнили народный артист Республики Татарстан Рустем Закиров, мусульманский ансамбль духовного и национально-народного песнопения «Иллаһиләр», шакирды РИУ ЦДУМ России, детская группа из уфимской мечети «Хамза» и гостья из Казани – финалистка шоу «Голос. Дети» Саида Мухаметзянова.

# НАД СЕЛОМ ЗАБЛИСТАЛ ПОЛУМЕСЯЦ НА МИНАРЕТЕ

Республика Башкортостан






**30 октября в деревне Старое Тимкино Балтачевского района, ведущей свою историю с начала XVIII века состоялось торжественное открытие новой мечети «Нур».**

В торжестве приняли участие жители села, а также приехавшие из городов их близкие и родственники, имамы из соседних районов и близлежащих деревень. С этим знаменательным событием сельчан поздравил глава администрации Балтачевского района И.А.Субушев, Верховный муфтий, Председатель ЦДУМ России, Шейх-уль-Ислам Талгат Сафа Таджуддин.

До революции в этом селе было два культовых здания, работало медресе, но затем наступили времена государственного атеизма. Два года назад местные мусульмане решили построить Дом Аллаhа и весной 2020-го дружно взялись за дело. «Каждый житель села по мере сил и возможностей вносил свой вклад в общее дело: деньгами (кто – сто, кто – тысячу, кто – десятки тысяч, а кто и сотни тысяч рублей), своим мастерством и умением, участием в субботниках», – о процессе возведения храма рассказал на своих страницах в соцсетях глава Администрации Балтачевского района Ильгиз Субушев.

Шейх-уль-Ислам, Верховный муфтий, Председатель ЦДУМ России Талгат Сафа Таджуддин в своем выступлении поздравил старотимкинцев с большим событием в их духовной жизни и отметил: «*...42 ел элек Башкортстанда 16 мәчет иде. Ил буенча 70 миллион мөселман яшәде, 340 мәчет булды. Безнең нәзарәткә караганы – 94. Республикада да мәчетләр салына. Әлеге вакытта Русия буенча 7500 мәчет салынды.*

*40 еллап Балтач районына килеп йөрим. Балтач өчләтә үсте. Зарланабыз, әмма дөнья алга бара. Балтачлылар батырлык белән дә, булдыклылык белән дә үрнәкле. Хәзер авылыгызда, әль-хәмду Лилләh, яңы мәчет!*

*«Аллаhы ризалыгы өчен бераү мәчет салганда кем дә булса такта китерсә дә, кадак какса да, мәчете кош оясы кадәр булса да, әҗерсаваплы булыр. Мәчет салганнарга Аллаh Собханаhу вә Тәгалә Җәннәттә сараен әзерлде», - ди Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.).*

*Кайчан якты дөньяга килүебез, китүебезне Аллаhы Тәгалә язып куйган. Әле мөселман илләрендә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) туган көнен билгеләделәр. Бу көндә якыннарны да искә алабыз, дога кылабыз. Дөнья бар. Бу дөньяны без төземәдек, Аллаhы Тәгалә бар итте. Күз, колак, куәт-көч биргән икән, бездән соң да балаларыбыз яшәсен, дөнья-әхирәт бәхетен ирешсен дигәндә мәчеткә килергә тиешле. Намазда кеше басканда «әлиф» хәрефе, бил белән бөгелгәндә «дал» хәрефе, сәҗдәдә – «мим» хәрефләре рәвешен ала. Әдәм димәктер. Сине таныйм, Сиңа шөкер кылам, җир йөзенә вакытлы командировкага җибәрдең, адәмлелегемне, әль-хәмду Лилләh, югалтмадым». Моны онытмас өчен мәчеткә килик, намазга басыйк.*

*Үткән елда, июль аенда референдум үткәрелде. Законга кергән мәгълүмат буенча ата-бабаларыбызның мирасын саклау өчендә, без Ватаныбызны, туган телебезне, милләтебезне кадерләп яшәргә тиешбез, димәк. Аллаhының йорты һәр авылыгызда да булуына шөкер. Аны Аллаhыдан башка бераүдән дә куркмый торган батырлар төзер».*

По завершению своего выступления Верховный муфтий передал общине знамя старейшего духовного управления страны, а затем наградил самых активных участников строительства Благодарственными письмами ЦДУМ России и вручил медаль «Аль-Игътисам» («Сплоченность») Имамгали Тимергалиеву (посмертно), служивший более полувека имамом мечети деревни Староякшеево. Медаль вручили его сыну. В рамках пасторского визита в Балтачевский район Шейх-уль-Ислам Талгат-хазрат посетил мечети деревень Усманово и Уразаево, а также музей просветителя XVIII века Габдуллы Галиева (Батырши) в Старобалтачево.



# XI ЕПАРХИАЛЬНЫЕ ТАБЫНСКИЕ ЧТЕНИЯ

## Представители традиционных конфессий обсудили проблемы секулярного мира

**11 ноября состоялись XI Епархиальные Табынские чтения. Тема церковно-общественного форума: «К 350-летию со дня рождения Петра I: секулярный мир и религиозность». Мероприятие, прошедшее в формате видеоконференции, было организовано при поддержке Министерства образовании Республики Башкортостан.**

Почетные гости чтений – Шейх-уль-Ислам, Верховный муфтий, Председатель ЦДУМ России Талгат Сафа Таджуддин; председатель Государственного Собрания – Курултая Республики Башкортостан Константин Толкачев; Главный раввин г.Уфа и РБ Дан Кричевский; председатель Совета по государственно-конфессиональным отношениям при Главе РБ Азат Фаттахов.

Во вступительном слове **Владыка Никон** сформулировал главную цель и задачи форума: «*Проблемы современного общества – тем более острейшие из них, такие, как проблемы утраты нравственных ориентиров, секуляризации общества и новых вызовов, связанных со стремительным распространением новых вирусов и общественных болезней, ставящих под сомнение будущее нашего народа, – нельзя обсуждать в отрыве от их духовно-нравственных причин*».

**Верховный муфтий Талгат Сафа Таджуддин** в своем выступлении обратил внимание на актуальность и жизненность темы XI Епархиальных Табынских чтений, подчеркнув: «*Родина у нас одна и едина, и какие бы изменения ни происходили, касаются они всех нас. Мир не может быть без веры в Бога и тех принципов жизни, которые установлены Им и доводились до человечества Его посланниками и пророками.*



*Я услышал сейчас от Владыки Никона печальные слова о секулярном обществе, все более удаляющемся от следования Божьим заповедям. Но отчаиваться нельзя!*

*Через 104 года государственного атеизма в 2020-м подавляющее большинство россиян проголосовало за поправки к Конституции, и важнейшая из них о том, что вера в Бога и традиционные духовно-нравственные ценности являются наследием наших предков. Создан Межрелигиозный совет России во главе с Его Святейшеством Патриархом Кириллом.*

*Немало проведено заседаний, и один из важнейших результатов этой работы – преподавание в школах курса истории и культуры традиционных конфессий. Мы видим, какое огромное внимание уделяет государство духовной жизни граждан. Например, сегодня в чтениях принимают участие представители местных властей, республиканских министерств и ведомств Башкортостана.*

*В Российской Армии растет число священнослужителей, имеется большая потребность в них, потому что наши воины в неспокойном мире призваны быть не просто людьми с оружием в руках, а высокодуховными личностями.*

*Слава Всевышнему, в Совете Федерации уже обсуждается насущный вопрос о введении уроков нравственности в средней школе и в вузах. Преподавание их предполагает участие духовенства всех традиционных конфессий.*

*Если сравнить наше время и то, что было в 1990-х годах и раньше, видны огромные изменения: не только увеличение храмов, мечетей, синагог, но и массовое подвижничество среди прихожан. Вера, религиозность и духовность не потеряны!*»

НОВОСТИ
ОНЛАЙН ТРАНСЛЯЦИИ МЕРОПРИЯТИЙ
И ПЯТНИЧНЫХ ПРОПОВЕДЕЙ

Верховный муфтий Талгат Таджуддин
https://vk.com/talgattadguddin

# В МЕДРЕСЕ «РАСУЛИЯ» ПРОШЕЛ ПРАЗДНИК МАУЛИД АН-НАБИ И ПОСВЯЩЕНИЕ В СТУДЕНТЫ

Челябинская область



**7 октября, в первый день месяца Рабигуль-Авваль, в медресе «Расулия» в торжественной обстановке было отмечено сразу два знаменательных события: «Отчет по производственной практике» и «Посвящение в студенты».**

По традиции собрание началось с чтения Священного Корана. Вот уже третий год студенты 2-го и 3-го курсов медресе направляются на практику в местные мусульманские организации Челябинской области. В ходе практики студенты закрепляют пройденный материал, приобретают опыт работы с людьми, а самое главное, оставляют людям полезные знания традиционного Ислама. Как отметили сами студенты, в такой практике есть большая польза и развитие для них самих, а также для тех, кому довелось донести эти знания.

После защиты практики в медресе состоялось торжественное посвящение первокурсников в студенты медресе «Расулия» (очников). Главный муфтий Урфо, председатель РДУМ Челябинской и Курганской областей Ринат хаджи-хазрат Раев и директор медресе «Расулия» Дамир-хазрат Биткулов вручили первокурсникам под сопровождение такбира именные Кораны и студенческие билеты.

«Приобретение знаний невозможно без учителя», - подчеркнул директор медресе Дамир-хазрат, отметив благодарственными письмами за успехи в профессиональной деятельности преподавателей медресе Салихова Ильнур-хазрата и Икромова Мухаммад-хазрата. Дамир-хазрат выразил слова благодарности всем присутствующим за помощь в организации и проведении мероприятия и за неоценимый вклад в дело религии Ислам.

Перед студентами медресе «Расулия» выступил муфтий Ринат хаджи-хазрат Раев. Он отметил важность прохождения практики, сказав, что это хороший способ проверить, насколько хорошо усвоен пройденный материал. Муфтий также поздравил первокурсников с новым этапом в их жизни, подчеркнув, насколько ценно приобретение знаний, не только религиозных, но и светских.

Ринат-хазрат Раев рассказал о перспективах развития медресе «Расулия», о проводимой ежегодной Международной научно-практической конференции «Расулевские чтения: Ислам в истории и современной жизни России» и о преображении г. Троицка.

**21 октября в мечети им. Зайнуллы Расулева по ул Октябрьской г. Троицка преподаватели и студенты медресе «Расулия» провели праздник Маулид ан-Наби – день рождения Пророка Мухаммада (с.г.в.), а также посвящение в студенты первокурсников медресе (заочников).**

Мероприятие началось с коллективного полуденного намаза и чтения Священного Корана. В начале праздника директор медресе Дамир-хазрат Биткулов в своем приветственном слове подчеркнул, что Маулид ан-Наби живет в сердце каждого истинного мусульманина и имеет для него очень большое значение.

Главный муфтий УрФО, председатель РДУМ Челябинской и Курганской областей Ринат хаджи-хазрат Раев поздравил всех присутствующих с наступлением священного месяца Рабигуль-Авваль, рассказал о значимости и важности проведения Маулида, так как это – день рождения последнего Пророка Мухаммада (с.г.в.). После приветственных слов Мухаммад-хазрат Икромов рассказал о жизни Пророка (с.г.в.), поведал интересные и поучительные истории и хадисы. Студент 1 курса медресе «Расулия»Закир Шакиров рассказал трогательную историю из жизни Пророка «о слепом, которого Пророк Мухаммад (с.г.в.) кормил из своих рук». После этого Салихов Саид и Шакиров Закир исполнили нашид.

В этот день также состоялось посвящение в студенты медресе обучающихся 1 курса заочной формы. Муфтий Ринат-хазрат Раев и директор медресе «Расулия» Дамир-хазрат Биткулов под звуки такбира торжественно вручили именные Кораны и студенческие билеты. Значком за активное участие в жизни медресе был награжден студент 1 курса Аккужин Ильгиз.

В завершении мероприятия студенты мужской заочной группы исполнили нашид и прочитали салават. От лица женской заочной группы Альфида Хакимова поблагодарила руководство медресе и хазратов за организацию учебного процесса. В этот благословенный месяц Рабигуль-Авваль участники торжественного мероприятия, руководство РДУМ Челябинской и Курганской областей, руководство медресе «Расулия» пожелали всем верующим стать достойным примером для всех, чтобы все деяния каждого были благими.

Подобные мероприятия уже входят в добрую традицию медресе «Расулия», неся в себе искренние наставления и пользу.

*Пресс-служба РДУМ Челябинской области*

## МЕДРЕСЕ «НУРУЛЬ-ИСЛАМ»

# МЫ ПРАЗДНУЕМ МАУЛИД АН-НАБИ ВЕСЬ МЕСЯЦ РАБИГУЛЬ-АУВАЛЬ И ВСЮ ЖИЗНЬ

**18 октября в медресе «Нуруль Ислам» ЦДУМ России состоялся Маулид, посвящённый месяцу рождения Пророка Мухаммада (мир ему и благословение). В отличие от предыдущих лет мероприятие провели только для студентов медресе, так как существующие ограничения в условиях пандемии не позволяли это делать широко и массово.**





Традиционно имам-ахунд Сибгатуллин Мавлемзан-хазрат обратился к студентам с речью, наполненной поучительным смыслом. Особое внимание он обратил на веротерпимость Ислама. «Очень важно подрастающему поколению не только передавать знания, но и воспитывать их на моральных ценностях Ислама. Наши затраты сегодня на нравственное воспитание и религиозное просвещение молодежи – это завтра сэкономленные койки в больницах, места в приютах и детских приемниках, домах для престарелых, сокращение количества заключенных и самое главное – противодействие экстремизму», - резюмировал он.

В завершение праздника шакирды прочитали мунаджаты и салаваты. Студенты, получившие еще один урок мудрости и благочестия, стали на один шаг ближе к заветной цели – стать истинным религиозным служителем.

## МЕДРЕСЕ «РАСУЛИЯ»





**В медерсе «Расулия» весь благословенный месяц Рабиуль авваль проходил конкурс детских рисунков на тему «Моя любимая сунна Пророка Мухаммада (мир ему)». 8 ноября медресе вновь наполнилась смехом детей, сияющими глазами и радостными улыбками - в этот день подвели итоги конкурса.**

По традиции директор медресе Дамир хазрат Биткулов поприветствовал детей и их родителей, а преподаватель Серик хазрат Бурумбаев прочитал суры из Священного Корана.

В конкурсе участвовали 25 детей, в том числе 12 детей из г.Троицка. Сначала в кругу детей провели знакомство и обсуждение их рисунков, поиграли в игры на закрепление сунн и терминов, пели салаваты и нашиды. Дети проявляли интерес и очень активно принимали участие, они поняли, что даже будучи такими маленькими, могут каждый день совершать сунну Пророка Мухаммада (с.г.в.) и получать за это вознаграждения. Атмосфера мероприятия была пронизана чувством любви к Пророку Мухаммаду (с.г.в.). Каждый рисунок был уникален и неповторим. Все участники конкурса получили грамоты и подарки, остальным участникам подарки отправятся по почте.

**Учредитель:** Центральное Духовное управление мусульман России
**Адрес редакции и издателя:** 450057, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. Тукаева, 50
**Тел:** (347) 250-80-86, **Факс:** 250-80-99
**Главный редактор:** Зубаерова И.М.

**Уважаемые читатели! Относитесь с почтением к газете, не используйте ее в недостойных целях!**

**Сайт:** www.cdum.ru
**e-mail:** maglumat@cdum.ru
Дата выхода в свет: 30.11.2021
**Объем:** 12 полос **Тираж:** 2000 экз.
*Заказ №7010*

Отпечатана в ООО РПК «Формула», 450001, Республика Башкортостан, г.Уфа, ул.Комсомольская, д.2, корпус 9
Цена бесплатная.

*Газета издается при содействии и финансовой поддержке некоммерческого благотворительного «Фонда поддержки исламской культуры, науки и образования»*

Газета зарегистрирована в Министерстве РФ по делам печати, телерадиовещания и средств массовых коммуникаций, св-во ПИ №77-11980 от 04 марта 2002 г.